


ГАЗЕТА СЕВЕРО-ЗАПАДА ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ | № 11 (14) | НОЯБРЬ 2009

## НОВОСТИ ТАТАРСКОГО МИРА

20 нче ноябрь көнне Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Ринат Закиров әлеге тантанага килгән шагыйрьнең якташларын, Башкортостанның Бишбүләк районы Аит авылыннан килгән мәктәп директоры Ильмир Шафиков, авыл башлыгы Рәсил Гыймазетдиновны, Ф.Кәрим музее директоры Рәисә Хафизова, район мәдәният бүлеге хезмәткәре Зөлия Исламованы кабул итте. Очрашуда шулай ук ТР язучылар Берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, «Азатлык» радиосының Казан бүлеге җитәкчесе, быелгы Ф.Кәрим премиясе лауреаты, якташлары Римзил Вәли дә катнашты. Түгәрәк өстәл артында очрашу җылы рухта узды. Кунаклар якташлары Фатих Кәримне хөрмәтләгәннәре өчен рәхмәтләрен җиткерделәр, киләчәктә бергәләшеп эшләү турында фикер алыштылар. Татарстан белән Башкортостан арасындагы дуслык күперен ныгытуда уртак чараларның зур роль уйнавы да әйтелде.

**tatar-congress.org**

* * *

В прошедшем месяце в селе Асекеево в офисе татарской автономии состоялась встреча председателя ТНКА Асекеевского района Ильдуса Давлятова и председателя ТОЦ «Туган тел» города Бугуруслана Хамзя Газизова, в рамках действующей ассоциации татарских объединений « Бердәмлек». Речь шла о развитии татарского телерадиовещания в регионе.

* * *

Депутат Законодательного собрания Оренбургской области Ильдус Давлятов традиционно поздравил мусульман своего избирательного округа с праздником Курбан байрам и выделил прихожанам мечетей средства на приобретение овец и баранов для жертвоприношения в праздник.

* * *

В середине ноября группа аксакалов Асекеевского района побывала в Казани, где им представилась возможность помолиться в знаменитых мечетях Татарстанской столицы — Кул Шариф и Марджани. Сотрудники Всемирного конгресса татар организовали для асекеевцев экскурсию по Казани. Поездку на автобусе организовал и оплатил Ильдус Давлятов.

* * *

Редакция газеты «Туган як. Родной край» совместно с почтовиками открыли подписку на первое полугодие 2010 года. Стоимость ее 94 рубля 50 копеек. Из этой суммы почти половина пойдут на оплату услуг связи и налоги. Газета с нового года будет выходить два раза в месяц. В настоящее время подобраны внештатные корреспонденты газеты в Абдулино и Пономаревке. Приглашаем к сотрудничеству журналистов и просто пишущих людей из других районов.

## Туган як- газета твоего родного края


ТУГАН ЯК РОДНОЙ КРАЙ

Расширенное заседание Совета ТНКА

Җыр яңгырый, моң яңгырый

Подворью быть

Правовой нигилизм наносит вред национальным интересам народа

Бөек Тукай аенда очр...

Мин татарча сөйләшәм

**Продолжается подписка на нашу газету «Туган як. Родной край» на первое полугодие 2010 года**

**Подписной индекс 53167. Далее на газету можно подписаться доставкой со следующего месяца.**

**Газета с 2010 года будет выходить ДВА РАЗА МЕСЯЦ.**

**Цена на полугодие 94 рубля 50 копеек. Подписаться можно во всех отделениях связи и у почтальонов.**

КУРБАН БАЙРАМ



# ПРАЗДНИК В КАЖДОЙ МЕЧЕТИ

В этом году праздник Курбан байрам совпал с пятницей. А пятница у мусульман и без того особый день. Уже с раннего утра в мечети потянулись люди, чтобы совершить праздничную молитву — гаит. В такие дни в дом Всевышнего приходят даже те, кого в обычные дни не часто увидишь в мечети. Такова традиция народа — начинать этот день с праздничной молитвы.

Асекеевская мечеть встретила сельчан приветливым светом окон. Аксакалы поздравляли друг друга с праздником и делились радостью со всеми остальными. Ильдар хазрат прочел праздничную проповедь, в которой рассказал о смысле этого праздника — в искренности и твердости веры.



И вот сама праздничная молитва. Она не долгая. Сразу после ее окончания прихожане восславили Всевышнего — милостивого и милосердного.

Ну а дома их ожидали праздничные блины и всякие вкусности.

По традиции, мусульмане побывали на кладбищах и поминали усопших родных и близких.

А вот в мечети поселка Чкаловский Асекеевского района байрам продолжили и во второй половине дня. Здесь организовали и провели праздничный обед. Ведь депутат Законодательного Собрания области Ильдус Давлятов выделил для прихожан целого барана. Вот и решили здесь отведать мясо жертвенного животного.

Сама мечеть появилась здесь не так давно. Под нее приспособили обычный частный дом, возвели небольшой минарет. И, что радует, мечеть стала настоящим культурно-просветительским центром для татар, проживающих здесь. Так Саима апа Мифтахова проводит здесь уроки арабского языка, рассказывает об исламе и традициях.

Небольшое здание еле вместило всех приглашенных. На лицах улыбки. Мусульмане искренне поздравляют друг друга, желают всех благ. Председатель Духовного управления Ассоциации мечетей, муфтий Асхат Шафигуллин, присутствующий на празднике, присоединился к поздравлениям и выразил искреннее восхищение сельчанам, сумевшим обзавестись мечетью.

После чтения сур корона и небольшой проповеди прихожане приступили к трапезе.

По окончании обеда мусульмане искренне поблагодарили И. Давлятова, других предпринимателей и сельчан за предоставленную возможность проведения такого праздника. Особо отметили непосредственных устроителей праздника. Пожелали всем мира, добра, здоровья и благополучия.

**Хаджи ФАРИТ.**

**На снимке:** праздничную проповедь ведет Ильдар хазрат; гаит в Асекеевской мечети; мечеть поселка Чкаловский, за праздничной трапезой.



МАСТЕР-КЛАСС

# ОН ВНОВЬ ПОКОРИЛ ЗРИТЕЛЕЙ

**Летом этого года у молодых талантов села Асекеево и соседних сел и районов было великолепная возможность обучиться танцу у настоящего мастера из Казани Венера Хамитова. Венер — главный балетмейстер казанского театра юного зрителя, старший преподаватель гуманитарно-педагогического университета. Но эти должности меркнут перед талантом самого танцора. По всему видно, что для артиста танец не только воплощение мастерства, но и образ восприятия и даже сама жизнь. Он живет в танце и своим обаянием, мастерством привлекает к себе последователей.**







Тогда мастер класс проводился в рамках Ассоциации татарских национальных объединений «Бердәмлек», по инициативе директора Асекеевского Дома культуры Зайтуны Валишиной. Ее поддержали председатель ТОЦ «Туган тел» г . Бугуруслан Х. Газизов, председатель культурно-просветительского общества «Туган тел» села Алькино Похвистневского района Самарской области Р. Латыпов. Ну а генеральным спонсором программы стал председатель татарской национально-культурной автономии Асекеевского района, депутат Законодательного Собрания Оренбургской области Ильдус Давлятов.



Концерт по итогам мастер класса тогда восхитил зрителей. А у многих подопечных Венера Хамитова стояли слезы на глазах. Они хотели продолжения обучения мастерству танца. И вот свершилось. Венер в ноябре снова приехал в Асекеево.

Известный в Казани танцор Венер Хамитов вновь показал сельским ребятам, что такое танец. Как посредством движения, пластики показать поэзию песни без слов. Особое внимание было уделено национальным танцам.

Одним из ноябрьских вечеров зал Дома культуры села Асекеево не смог вместить всех желающих. Концерт без единой остановки шел почти два часа под нескончаемые аплодисменты и «Браво!». По итогам второго мастер-класса был поставлен концерт, в котором свое искусство показали и сам мастер, и приобщенные к танцу ребята.

И самые маленькие и постарше, ребята показали настоящее высокое искусство. Ну сам мастер был просто неподражаем на сцене. Татарские, башкирские, китайские, еврейские, индийские танцы. Перевоплощение было настолько глубоко, что будто вместе с танцором переносишься в такт музыки в степи Башкирии и долины Ближнего и Дальнего Востока. По окончании концерта Венеру Хамитову была вручена благодарность от имени главы Асекеевского района. Зайтуна Валишина под одобрительные возгласы ребят и зрителей пригласила Венера Хамитова вновь посетить наше село и поделиться мастерством.

**На снимках:** на итоговом концерте.

МАЛЫЙ БИЗНЕС

# Нашли свою нишу

— Девочки, сможете мне штанины сузить, а то они широкие, болтаются как колокола, — обратилась полноватая женщина к портнихе, показывая на укороченные свои брюки.

— Ага, и будете как чупа — чупс: широкий верх и узкий низ, — бесстрастно ответила та, — а давайте мы вам лучше сошьем юбку — годе. Вашей фигуре очень хорошо подойдет, — добавила с милой улыбкой.

Такой курьезный диалог я услышала в ателье «Стиль» в с. Пономаревка, где, как выяснилось, есть очередь на выполнение заказов. Клиентов оказалось предостаточно. Что и неудивительно. Здесь не просто шьют красивые наряды и не хватаются за любой заказ, а еще дают рекомендации. Говорят ведь, что со стороны видней. Особенно профессиональным мастерам-швеям.

Небольшое ателье принадлежит Юлии Саматовне Сайдашевой, которая не только управляет всеми делами, но и сама шьет, помогая своим подчиненным — двум девчонкам: Римме Вахитовой и Лейсян Сагдуллиной.

Хозяйку этого заведения Юлию Саматовну можно назвать опытной мастерицей. До открытия своего дела она много работала за швейной машинкой. С детства мечтала шить сказочные, бальные платья. Поэтому после школы пошла на учебу в Ташкентский политехнический техникум на модельера-технолога. До своего переезда в Пономаревский район Юлия Сайдашева жила в Ташкенте, где после окончания учебного заведения работала в шубном цехе сначала швеей. Верхняя одежда — вещь капризная. Не многим дается шитье шуб, пальто. Мех да тяжелая ткань требуют особого обращения, чтобы на них получились ровные, аккуратные строчки. В то время изделия республиканского цеха славились в России, где продукция фабрики пользовалась спросом. Здесь-то Юлия Саматовна и «набила» руку, причем, так успешно, что уже через три года стала заведующей.

Рабочие планы прервала переселенческая волна. Ей поддалась и молодая семья Сайдашевых (Юлия к тому времени уже была замужем и воспитывала сына). Не долго думая, супруги переезжают в село Нарузово — туда, откуда корни Юлии. На первое время остановились в доме бабушки и дедушки, куда приходили ее первые заказчики. На новом месте про ее мастерство быстро узнали. Три года она сама кроила и шила на дому, после чего хозяйка Пономаревского ателье Р. М. Сахибгареева пригласила ее на работу. Однако год спустя предпринимательница свернула свою деятельность, посчитав ее убыточной.

И тогда бразды правления взяла в свои руки Юлия Сайдашева. Она юридически зарегистрировалась как индивидуальный предприниматель, снова открыла ателье, о чем сегодня не жалеет. На себе ощутила, что государство стимулирует предприимчивость. А ведь могла бы еще не знай сколько поддерживать ряды безработных в Центре занятости населения, (туда встала на учет после первого закрытия швейного предприятия), где ей и подсказали идею начать свое дело. Даже безвозмездную субсидию по федеральной программе стабилизации на рынке труда дали. Помощь государства в сумме 60 тысяч рублей теперь позволят Юлии, вчерашней безработной, покрыть долги, взятые на приобретение швейных машин.

Сегодня девчата в ателье строчат, прерываясь лишь на короткие паузы во время приема клиентов. Есть уже постоянные заказчики. В ателье заказывают кройку и шитье юбок, блузок, костюмов, платьев. Люди, имеющие свой индивидуальный вкус, предпочитают делать покупки не на розничном рынке, избегая типичности в нарядах. Они выбирают креативные вещи, над творением которых корпеют в этом маленьком ателье. Помимо шитья, заказчики приносят одежду на ремонт. Домохозяйки заказывают по индивидуальному варианту шторы, ламберекены, желая украсить интерьер дома. А какие чудесные, нарядные платья будто для принцесс на выпускной бал шьют. В ателье приезжают даже из отдаленных сел района.

Поэтому здесь сложилась даже очередность, что подталкивает Юлию Сайдашеву на расширение дела. Задумок у нее много. Хотелось бы, например, заняться шитьем автомобильных чехлов, обивкой мебели и т.д., а получится или нет, покажет время. Но, как говорится, было бы желание и усердие. Ведь смогла же хрупкая и молодая женщина обеспечить не только себя работой и источником средств к существованию, но и еще двух девушек. Больших денег они пока не зарабатывают. Но, думается, у них все впереди, так как ателье набирает обороты и с каждым днем подтверждает свою востребованность.

**И.СУЛЕЙМАНОВА.**
**с.Пономаревка.**

КҮРШЕЛӘРДӘ

# Гали авылына — 400 ел!

Татарстан фәннәр Академиясенең Шихабетдин Мәрҗәни исемендәге тарих институтыннан Гали аулына куанычлы язма килеп төште. Бу тарихи белешмә өлкәнең Гали аулына нигез салу турында.

Рус патшалары Михаил Федорович, Иван Алексеевич, Петр Алексеевич имзалаган документлар тупланмасында бүгенге Гали аулына кагылганнары да бар. Бу документта түбәндәге юллар бар:»...отец матери Миняша (Монаша) Гульбастан был пожалован ханом Ибрагимом тарханной грамотой.»

Гөлбостанның атасына Ибраһим хан тарханлык биргән булган. Ә ул заманда тарханлык гаҗәеп зур өстенлекләр биргән адәм баласына. Казан архивларында Гөлбостан — хатынның улы Мөхәммәд –Азизханга бирелгән тарханлык ярлыгы сакланган. Миняшларның нәсел ырыуын, шәҗәрәсен тикшереп чыккач, рәсми кәгазьләр шуны күрсәтәләр. Тархан Булат Монашев Кинель елгалары буйлап кондыз ауларга рөхсәт кәгазе ала. Бу документ 1613 ел белән теркәлгән. Әлбәттә бу инде икенче теркәү. 1467-1479 еллардагы Ибраһим хан Монашевларның бабаларының бабаларына ук тарханлык биргән булган бит.

Тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков имзалаган һәм мөһер суккан документта Монашевларның ерак бабалары нигез салган Гали аулының тарих башын 1613 елдан башларга тәкъдим ясалган., ә чынында исә Али бабайга тарханлык әле 1479 елны ук бирелә.

Борынгы «Али» рус мохитендә Гали булып түгел, ә «Алькино» булып китә.

2013 елны Галигә 400 ел булачак.Самара дәүләт архивы белешмәләренә караганда, Гали авылы 1871елда Стюхино волостенә керә. Авылда 288 йорт булып, ир-атлар 842 кеше, хатынкыз 866 кеше була. Барлык җирләр халыкның хосусый милкенә керә. Авылда өч мәчет һәм су тегермәне төзелә. Ә 1900-нче елда инде йортлар саны 304 булып, анда 1708 кеше яши.

Гражданнар сугышы елларында власть берничә тапкыр кулдан- кулга күчә. 1917 елда авыл Советы оештырыла. Нәбиулла Вәлиуллин рәис булып сайлана. Колхозлашу елларында авыл хуҗалыгы артеле «Кызыл юл» һәм «Тургай» төзелә. Председателе Алтынбаев Хәбибулла була.

1952 елда артельләр кушыла. 1953 елда Шакир углы Фатыйх Тарзеев рәис итеп куела. 1956 елдан «Кызыл юл» колхозы «Тарзеев» колхозы итеп исемләнә. Колхозда кош-корт, эре мөгезле терлек, сарыклар үрчетәләр.

1964 ел. Әсәдулла улы Сәйфулла Сафиуллин бертавыштан колхоз председателе булып сайлана. Ул хуҗалык иткән елларда авылда бик күп эшләр башкарыла. Агач кашыклар, савыт-сабалар ясау өчен остаханәләр ачыла. Бер-бер артлы сөтчелек фермасы өчен биналар төзелә.

Тракторлар ремонтлау остаханәсе барлыкка килә. Асфальт юл салына. Өйләргә газ кертелә. Мәдәният йорты, өч катлы мәктәп бинасы, колхоз идарәсе йорты төзелә. Колхозга яңадан-яңа машиналар, тракторлар кайта. 1989 нчы елга чаклы колхозчы хатын-кызлар тегү остаханәсендә эш киемнәре, бияләйләр тегәләр.

1990-нчы ел. Тормыш шартлары аркасында колхоз бөлгенлеккә төшә. Хөкүмәткә бурычы артканнан арта. Ә 1999-2000 елларда ул бөтенләй таркала. Колхоз таркалса да, авыл халкы чәчүлек җирләрне буш калдырмый, чүп үләне үстерми. Эшмәкәр Наил Баһаутдинов, Камил Исхаков, Әбузәр Гәрәев, Рамил Харисов бу җирләрдә иген, көнбагыш үстерәләр.

Гали авылында бүгенге көндә 705 йорт исәпләнә. Шуларда 2140 кеше яши. Авылның йортлары тирә-яклар өчен үрнәк булып тора, ә халкы бик уңган. Һәр хуҗалык керем өчен суган, кишер, кыяр үстерә. Күп кенә хуҗалыкларда помидор үстерү өчен теплицалар ясалган. Халыкның тормышы яхшы, бу аның тырышлыгына бәйләнгән.

Авылда Расих Латыйпов тарафыннан ачылган колбаса җитештерү цехы «Хәләл» эшләп тора. Алар җитештергән ашамлыкларны илебезнең төрле почмакларына күрергә була. Рамил Мостафин авыл халкы өчен тегермән ачса, Сәйфулла Маннановның ике кибете тормыш-көнкүреш өчен кирәк булган барлык әйберләр һәм азык — төлек белән тәэмин итә.

Наил Баһаутдиновның, Ильяс Арслановның, Камил Руслангалиевның май чыгару цехы уңышлы гына эшләп килә. Гали авылы волосте администрациясе, мәдәният йорты, шифаханә, китапханә, элемтә бүлеге, кәрәзле телефон салоны халыкка хезмәт күрсәтә.

Чуваш авылы Рысайкино белән Гали авылының нәкъ чигендә өч катлы мәктәп бинасы урнашкан. Монда галилеләрнең балалары белем һәм тәрбия алалар. Күптән түгел Гали авылы мәктәбе үзенең 100 еллык юбилеен билгеләп үтте.

**С сайта татарской общины Самарской области www.tatarlarsamara.ru**



**В издательство «Татарская книга» г. Казани вышла книга Рашита Искандарова о татарах Оренбургской области. Наш край — северо-запад Оренбургской области — представлен в ней очень скромно. Так, Асекеевскому району, где большинство населения татары, посвящено 12 страниц книги из 270. А селу Асекеево одна страница. В основном автор опирается на труды Попова, Кузеева и Стрельникова согласно которым Асекеево основано вовсе не татарами. А нынешние татары, оказывается, башкиры.**

**Автору книги претензий нет. Он пользовался источниками, которые были опубликованы еще в прошлом веке. А вот мы — асекеевцы — получается, не помнящие родства. Ничто нам не мешало докопаться до подлинной истории села по примеру алькинцев, а не пользоваться легендами. Они и работать умеют, и историю чтят. Видимо, потому Гали авылы выбрано для проведения общефедерального сабантуя в 2010 году.**

**Редакция газеты поздравляет Расиха Латыпова — председателя культурно-просветительского общества «Туган тел» села Алькино с избранием в исполком Самарской областной татарской автономии. Следует напомнить читателям, что это общество наряду с татарской национально — культурной автономией Асекеевского района, татарским общественным центром «Туган тел» города Бугуруслана, учредили Межрегиональную Ассоциацию татарских национально-культурных объединений Оренбуржья и Самарской области «Бердәмлек». На счету этого объединения уже много добрых дел.**

# Самара татарлары берләште

29 октябрь самара өлкәнең татарлары тариһында кызыл көн булып калачак. Чөнки шул көндә Самара өлкә автономиясе барлыкка килгән. Бу көнне күпләр бик көтеп алган. Чөнки Самара өлкәсендә татарлар күп булса да, аларны берләштерә торган бер оешма һаман юк иде. Беренчедән, Самара, Тольятти, Сызран шәһәрләренең татар — милли автономияләре карар нигезендә Самара өлкә региональ автономиясен тезү буенча оештыру комитеты булдырылды, икенчедән, комитет уз эшен бетергәч, конференция оештырырга да вакыт. Нәкъ агымдагы елның 29 октябрь көнне Самара өлкә милли — мәдәни автономияне оештыру конференциясе узды. Җирле автономияләрнең вәкилләре Самара шәһәренең «Яктылык» мәктәбендә җыелганнар иде. Алар арасында Сызрань, Тольятти, Самара шәһәрләре һәм Гали, Денис, Камышлы авыллары. Җыелышны Русиянең атказанган төзүчесе Вазыйх Мөхәммәтшин алып барды.

Бөтендөнья татар когрессының Башкарма комитеты рәисен, Ринат Закировны, җыелышта катнашучылар игътибар белән тыңладылар. Ринат Зиннур улы Закиров төрле төбәкләрдәге, хәтта чит илдәге татарларның тормышы турында сөйләп күрсәтте. Һәм алар белән чагыштырып, Самара татарларның эшен хуплады.

Автономиянең исполкомына Дания Абрахимова, Вазых Мухаметшин, Якуб Камалов, Фахретдин Канюкаев, Илгиз Колючев, Фархат Махмутов, Минахмет Халиуллов, Рифкат Хузин (Самара), Җамил Валиуллин, Рашид Нурмухаметов, Саубан Рафиков, Рустам Якупов (Тольятти), Илсур Гильманов, Рахимжан Мингалишев (Сызрань), Расих Латыпов (Алькино) керделәр. Яңа автономиянең рәисе булып Халиуллов Миңнәхмет Мухтарович сайланды.

# Татарлыкка бер адым

**Миндә ага татар каны.**
**Мин горур татар булуыма.**
**Мин татарча сөйләшәм.**

Минем өчен бу гади җөмләләр түгел. Бу сүзләр белән минем иртә-кичләрем уза. Үз милләтем белән нык бәйләнгәнмен. Әгәр бүген миннән сорасалар: «Нәрсә өчен гомереңне бирергә әзерсең?». Бердә уйламыйча: «Милләтем өчен», — дияр идем. Юк, мин сезне гомерегезне кырга чакырмыйм, ләкин үзегезне кем икәнлегегезне онытмаска киңәш бирәм. Татар — горур һәм белемле халык булган һәм булырга тиеш.

Мин үзем өчен яңа тойгы, яңа хис ачтым — «татарлык» дип атала ул. Аның нәрсә икәнен сезгә дә аңлатасым килә. Бу мәкаләне укыгач, сез үзегездә дә бу хисне эзләп табырсыз дип ошанам. «Татарлык» ул гади, көнкүреш әйберләрдән җыела.

Беренчедән, карагыз, санагыгызның эш өстәлендә нинди рәсем тора? Миңарда — «Зәңгәр шәл» спектакленнән төшерелгән фото — милли кием кигән артистлар сәхнәдә тезелешеп утыралар. Сез матур табигать төшкән рәсем куйгансыз? Берүк кәефегез төшмәсен, «татарлык»та әле тагын ничә сыйфатлар бар әле.

Икенчедән, социаль челтәрләр хәзер бик популяр. Әгәр дә сез «Вконтакте» яисә «Одноклассники»ларда утырмыйсыз икән, бу пункт сезнең өчен түгел.

Әгәр көн дә бу сәхифәләргә кереп — чыгып йөрисез икән, уйлап карагыз, сез кайсы төркемнәрдә төркәлгәнсез? «Салават иҗатын хөрмәт итәм» яисә, «Контакт татар телендә» сезнең списокта булса, сез «татарлык»ка илткән юлдан барасыз.

Өченче — телевизор. ТНВ каналы сезнең телевизорда кайсы каналда тора? Беренче? Унынчы? Әллә бөтенләй оныткансызмы? Уилавымча, монда комментарийлар артык булачак.

Дүртенче — плеерда яки музыкаль үзәгегездә нинди музыка уйный? Илхам Шакировмы әллә Филипп Киркоровмы? Бу пунктта да үзегез нәтиҗә чыгара алырсыз дип уйлыйм.

Бишенчедән, кәрәзле телефонда уйный торган музыка. Сез автобуста барганда телефоныгызны нинди режимга куясыз? Мин, мәсәлән, иң көчле тавышка куям. Янымдагы пассажирлар «Дөньяда күп нәрсә белдем, син туган тел аркылы»ны аңламасалар да, минем урыс түгелемне сизеп торсыннар!

Алтынчы, автобус темасын дәвам итәбез. Автобуста туган телегездә сөйләшергә ояласыз икән, «татарлык» хисен тоя алалмавыгыз да бар.

Җиденче, яраткан төсегез нинди? Яшел булса — йә сез «татарлык»ка омтыласыз, йә, психологлар фикеренчә, сез тормышта тынычлык эзлисез.

Азакы, һәм, минемчә, иң мөһим сыйфат. Балаларыгызга игътибар бирегез — йөрәк җимешләрегез татарча сөйләшәме? Әгәр, әлегә бала тудырырга өлгермәгәнсез икән, уйлагыз, кызыгызга яки улыгызга киләчәктә ничек дәшерсез һәм ул сезгә нинди җавап кайтарыр?

Әлбәттә, бу кечкенә шаян тест милләтнең тирән мәгънәсенә төшеп бетәлми. Ләкин, минемчә, уйланыр нәрсәләр бар. Әгәр сез бүген үзегезгә: «Ник соң мин һаман чит телендә сөйләшәм», — дип сорау бирсәгез, минем сүзләр юкка узмаган.

**Алсу ХАФИЗ.**
**Тольятти шәһәре.**

# Хәтерлим бала чагымны!

Сугыштан соңгы еллар. Безнең гаиләдә җиде кеше. Пенсия яшендәге әбием, бабам (ул чакта пенсия бирмиләр иде кебек), әти, әни, мин тәүге малай булып дөньяга килгәнмен һәм ике энем: Динар һәм Вабил 1941, 1945 нче елгылар. Гаиләдә фәкыйрьлек, ачлык хөкем сөрә иде. Авылда бер без генә түгел, бездән дә фәкыйррәк, ныграк интегүчеләр булган, билгеле.

Хәтеремдә калган: яз вакыты, әнием колхоз эшеннән соң, балтырган көпшәләре җыеп кайта иде. Су буенда йорт-җире белән, яшелчә үстереп көн күргән ике өлкән кешеләр- Сафа бабай карчыгы белән, җитеп килгән чөгендер яфрагын аш пешерергә әниемә бирә торган булганнар.

Кичен без гаиләбез белән җыелешып, ишек алдында, чирәм өстенә ашъяулык җәеп, кичке ашны ашыйбыз. Әнием табынга керешле калай белән мөлдерәмә тулы яшел чөгендер һәм балтырган ашын китерә. Ул ашны безгә, балаларга, алюмин савытларга салып бирә. Бу сугыштан соң һәртөрле һөнәрчеләр ясап базарда күренә башлаган, халык арасында кулланууда булган, яньчелеп беткән, бабам эшләпәсенә охшаган ярты литр керешле савытлар булып, ул савытларны әтием вакыт-вакыт чүкеч белән чүкеп, ипкә кертеп тора иде.

Бердәнбер кәҗәбез ике бәрән китергәч, яшел ашыбыз сирәк кенә булсада, агаргалый башлады. Әнием әйтүе буенча, сыерыбыз зыянлап, сугыш азагында үлгән.

Өйдә он азыгы да юк иде шикелле.Нәрсәгәдер алышып берничә кадак, яртысы кибәктән торган, солы оны бар. Аны кул иләге аша иләп, бәрәнге бакчасында җәйгелек өчен берничә кирпечтән ясалган учак өстенә таба куеп, Гайнекамал әбием ике яшьлек Вабил энемә уч төбедәй җәймә пешереп бирә иде. Бик сирәк очракта ул Динар энем белән миңа да әләгеп куйгалый. Аның тәмлелеге!... Теләнне йотарлык булып тоела!

Әтием сугыштан култык таякларына таянып кайтып төшкәч тә, язын сугышка кадәр колхозда тракторчы буларак эшләү сәбәпле, МТС рөхсәте белән ХТЗ маркалы, шпора тәгәрмәчле, керосин белән эшли торган тракторга утырттылар. Бәлкем, ул үзе генә белгәндер, тәзләргә да уйламаган яралы аяклар белән, ни дәрәҗәдә кыенга туры килгәнен. Без, малай-салай, өйдәге очсызкырыйсыз бала-чага башкара торган мәшәкатьләрдән бушаган арада, көн саен тракторлар эшләп торган җиргә, бригадага чабабыз. Әй, кызык та карап торулары! Әтием култык таякларын руль янындагы рычагка элеп куя да, аксаклап барып керосин краның ача, нәрсәдер баскалый, нәрсәдер тарткалый һәм кабыза торган «рукоятка» диеп аталган кәкре тимергә барып тотына. Гарип уң аяк тезен бик яхшылап үткен пластиналы ал тәгәрмәчкә төри дә, көч белән әйләндерә башлый.

Бүтән иптәшләрем алдында мин яшерен горурлык тоя идем. Чөнки әтием бу тимер гыйфриткә утырып, аны күндәм җиганләп, төтен чыгара-чыгара китеп бара. Ул вакытта тракторист бәлкем, хәзерге летчик-космонавтка тиң бугандыр?

Хәзер искә алам: ул елларда колхозда эшләр бик тә каты булган. Урак вакыты җитсә, әнием барлык колхозда эшләүче апалар белән бергә, кырдагы стан йортында куна ятып эшли иде. Өйгә кайтып әләгүләр бик тә сирәк булган. Әтием дә өйгә кайта алмый, кырдагы тракторлар «вагонында» куна торган иде. Аена бер кайтып та йортын күрми иде шикелле. Ә бабам инде олы яшьтә булуына карамастан, колхоз эшләренә даими катнаша, урак башыннан кибән куярга, башка эшләргә йөри. Ул бик оста, абруйлы кибән куючы, салам, печән өйгәндә өстә торучы булган. Озын-озын арыш көлтәләрен камылын тышка бик матур һәм яңгыр үтмәслек итеп югары төзә иде. Төш җиткәч тә төшеп йөрү юк, күмәк казанда пешкән сыек кына арыш умачын озын сәнәккә элеп, солдат котелогы белән кибән башына бабама биргәннәре хәтеремдә.

Олы яшьтәге әбием авыру булу сәбәпле, без, балалар белән мәш килә. Ә инде авылдагы бар халык, бала-чагалар, үз-үзен йөртә алган олы кешеләргә, һәммәсе дә басуда эштә. Бик кирәкле йомыш чыкканда да, колхоз эшеннән калып булмый иде дип, әнием сөйли иде.

Әнием бик тырыш булган: кайчакта кайтып безнең хәлне дә белеп китәргә өлгергән, бер караңгыдан икенче караңгыга калып көлтә бәйләгән. Шуның өчен башкалар белән бергә колхоз аңа көндә бер стакан он биргәннәр. Шул арыш оны безнең табынга азмаз үзгәреш керткән, чөнки сыек булса да, умач ашы кенә бер мәртәбә ясарга мөмкинлек булган.

Хәтеремдә, мин тәлинкәне шыпырдатып беткәнен, урамда иптәшләрем көтеп торалар. Малай чагымда бик шәп йөгерә идем, беркемгә дә узарга бирмәдем. Шуңадыр инде иптәшләрем «атлы» уйнаганда, минне ат итеп куялар иде.

Уйлап карасаң, авыл халкының дөнья көтү, көнкүреш мәсьәләләре, мәшәкатьләре чиктән ашкан булган. Авылдан ерак булмаган зур урман. Ләкин анн, ботак-чатак «уф-алла» арбасына салып кайту бик каты тыелгангамы , бәлки колхоз эшеннән бушый алмыйча, җәй саен кышкылыкка ягулык хәстәрләү проблемасы һәркемнең үзенә үткән. Шуңа күрә, кыш башыннан ук, мал-туар астыннан чыккан һәм колхоз ат абзарыннан чиратка язылып ташыган тиресне, ишек алдына өйгәннәр. Бер вакыт туры китереп (билгеле инде, колхоз рөхсәт биргәч), арыш урагына төшәр алдыннанмы, бәлки язгы чәчүдән соңмы, авыл кизәк ясау «туена» тотынган. Мичкәле арба башында утырырдай малайлар инештән ат белән су ташый, әни күршетирә апалар белән мичкәгә су тутырып торалар. Ат белән изелә торган басым кие саз кебек хәлгә килгәнче таптала. Икенче көнне өмә ясап, яки аз гына түләп, аларны формаларга (калыпка) салып ишек алдына тезеп куялар. Аны әйләндерү, киптерү, зуратка салу, көзге яңгырлар башланганчы кертеп түбә астына җыюлар… Колхоз эшенә дә өлгер, үз эшеңә дә… Ничек кенә чыгыша алгандыр халык!

**(Дәвамы киләсе номерда).**

**Рамис ГИЗАТОВ,**
**Яңа Тирес авылы,**
**Абдулин районы.**



# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

(время местное)

| ДЕКАБРЬ | Фаджр Иртә | Восход Кояш чыга | Зухр Өйлә | Аср Икенде | Магриб Ахшам | Иша Ясту |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 8-23 | 9-23 | 14-10 | 15-21 | 17-21 | 18-51 |
| 2 | 8-24 | 9-24 | 14-10 | 15-20 | 17-20 | 18-50 |
| 3 | 8-26 | 9-26 | 14-10 | 15-19 | 17-19 | 18-49 |
| 4 | 8-28 | 9-28 | 14-10 | 15-18 | 17-18 | 18-48 |
| 5 | 8-29 | 9-29 | 14-10 | 15-17 | 17-17 | 18-47 |
| 6 | 8-30 | 9-30 | 14-10 | 15-17 | 17-17 | 18-47 |
| 7 | 8-31 | 9-31 | 14-10 | 15-17 | 17-17 | 18-47 |
| 8 | 8-33 | 9-33 | 14-10 | 15-17 | 17-17 | 18-47 |
| 9 | 8-34 | 9-34 | 14-10 | 15-17 | 17-17 | 18-47 |
| 10 | 8-35 | 9-35 | 14-10 | 15-16 | 17-16 | 18-46 |
| 11 | 8-36 | 9-36 | 14-10 | 15-16 | 17-16 | 18-46 |
| 12 | 8-37 | 9-37 | 14-10 | 15-16 | 17-16 | 18-46 |
| 13 | 8-38 | 9-38 | 14-10 | 15-16 | 17-16 | 18-46 |
| 14 | 8-39 | 9-39 | 14-10 | 15-16 | 17-16 | 18-46 |
| 15 | 8-40 | 9-40 | 14-10 | 15-16 | 17-16 | 18-46 |
| 16 | 8-41 | 9-41 | 14-10 | 15-16 | 17-16 | 18-46 |
| 17 | 8-41 | 9-41 | 14-10 | 15-16 | 17-16 | 18-46 |
| 18 | 8-42 | 9-42 | 14-10 | 15-16 | 17-16 | 18-46 |
| 19 | 8-43 | 9-43 | 14-10 | 15-16 | 17-16 | 18-46 |
| 20 | 8-44 | 9-44 | 14-10 | 15-16 | 17-16 | 18-46 |
| 21 | 8-44 | 9-44 | 14-10 | 15-16 | 17-16 | 18-46 |
| 22 | 8-44 | 9-44 | 14-10 | 15-17 | 17-17 | 18-47 |
| 23 | 8-44 | 9-44 | 14-10 | 15-17 | 17-17 | 18-47 |
| 24 | 8-45 | 9-45 | 14-10 | 15-18 | 17-18 | 18-48 |
| 25 | 8-45 | 9-45 | 14-10 | 15-19 | 17-19 | 18-49 |
| 26 | 8-45 | 9-45 | 14-10 | 15-20 | 17-20 | 18-50 |
| 27 | 8-46 | 9-46 | 14-10 | 15-21 | 17-21 | 18-51 |
| 28 | 8-46 | 9-46 | 14-10 | 15-21 | 17-21 | 18-51 |
| 29 | 8-46 | 9-46 | 14-10 | 15-22 | 17-22 | 18-52 |
| 30 | 8-46 | 9-46 | 14-10 | 15-23 | 17-23 | 18-53 |
| 31 | 8-46 | 9-46 | 14-10 | 15-24 | 17-24 | 18-54 |

**Данные предоставлены Бугурусланским муфтиятом.**
**Возможна разница во времени в сравнении с другими источниками, на 3-5 минут.**




## Кыстыбый

Кыстыбый готовят из бездрожжевого теста. Для 1 кг теста необходимо 500-700 гр. муки, 200 — 250 г воды или молока, 30 г сахарного песка, 100 г масла, 2 яйца, соль. Воду или молоко тщательно смешивают с сахарным песком, солью, яйцами и маслом. Затем добавляют просеянную муку и замешивают тесто до тех пор, пока оно не перестанет прилипать к рукам и краям посуды.

Дав немного «постоять» тесту, разделить его на куски по 75 г, каждый из которых раскатать, поджарить на сухой сковороде сначала одну, потом другую сторону. Готовые пласты накрыть полотенцем, чтобы оставались мягкими.

Для начинки готовят картофельное пюре: добавляют в него горячее молоко, топленое масло, обжаренный без жира лук. Все смешать. На половину пласта кладут начинку, другой половинкой накрывают.

Смазать сверху топленым маслом. Готовые кыстыбы укладывают на сковороду, закрывают крышкой и ставят в духовку на 10 — 15 минут.

Кыстыбый подавать к столу горячими, вместе с топленым сливочным маслом.

## Кош теле

На 1 кг муки: 10 яиц, 100 г молока, соль, для жарки 600 г топленого масла, для теста 30 г сахарного песка, для посыпки сверху 100 г сахарной пудры, немного чайной соды.

В миску положить сахарный песок, яйца, молоко, соль по вкусу, чайной соды и мешать до полного растворения сахарного песка. Затем добавить муку столько, чтобы получилось крутое тесто.

Тесто раскатать толщиной в 1 — 1,5 мм и ножом разрезать на ленты шириной 3 — 3,5 см. В свою очередь ленты разрезать на параллелограммы длиной 4 — 5 см и приготовить на кипящем жире. Дать остыть, посыпать сахарной пудрой, уложить в вазы.


ТУГАН ЯК
РОДНОЙ КРАЙ

**E-MAIL:** tugan-iak-asekeevo@yandex.ru

**УЧРЕДИТЕЛЬ:**
ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНО КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
**АДРЕС РЕДАКЦИИ:**
С.АСЕКЕЕВО, УЛ.ЧАПАЕВА 24.
**ТЕЛЕФОН:** (353-51) 2-22-81

Распространяется в Асекеевском, Абдулинском, Бугурусланском, Матвеевском, Пономаревском, Северном районах.
Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ56-00065, выданное Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи и массовых коммуникаций по Оренбургской области.

Газета отпечатана в Бугурусланской типографии.
461600, г. Бугуруслан, ул. Революционная, 14.
Цена свободная. ТИРАЖ: 2000 ЭКЗ.

**Главный редактор: Фарит НУГУМАНОВ**